ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2022 г. Заинск № 66

**«Зәй муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентның үз көчен югалтуын тану турында»**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелек) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып,

## карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 33 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Н. Кулагина
(85558)7-08-18